МАМАДЫШ-АКИЛОВСКИЙ
СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МАМАДЫШ-ӘКИЛ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Мамадыш- **КАРАР**

**2024 елның 05 декабре** Әкил ав. **№ 19**

Зеленодольск муниципаль районы Мамадыш-Әкил авыл җирлеге Башкарма комитетының Зеленодольск муниципаль районы Мамадыш- Әкил авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 01 сентябрендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Мамадыш-Әкил авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең баш администраторларының бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Мамадыш-Әкил авыл җирлеге башкарма комитеты
**КАРАР ИТӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Мамадыш-Әкил авыл җирлеге Башкарма комитетының Зеленодольск муниципаль районы Мамадыш-Әкил авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 01 сентябрендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Мамадыш-Әкил авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәре баш администраторларының бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктның «б» пунктчасының алтынчы абзацында «тапшыру» сүзеннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләү гамәлгә ашырылган көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә.

1.2. 5 пунктның «б» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү;

бюджетка түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның Россия Федерациясе

Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән регламентын билгеләү;

Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр порталының Интернет челтәрендә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Мамадыш-Әкил авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча игълан итәргә: Мамадыш-Әкил авылы, Ленин ур., 50 йорт (җирлек администрациясе бинасы); Татар Танае авылы, Үзәк урамы, 1а йорт (авыл мәдәният йорты бинасы); Паново авылы, Үзәк бина, 26в йорт (авыл клубы) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Мамадыш-Әкил авыл Җирлек башлыгы,
Совет рәисе: Ф.Ф.Мирхәтуллин